| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШКАЙБИЦКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«12» октябрь, 2021 ел Олы Кайбыч ав. № 27

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 сентябрендәге 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 сентябрендәге 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 16 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының әлеге Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турында карары проекты, территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне планлаштыру документлары составында әзерләнгән территорияне ызанлау проектлары, җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү, рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү мондый рөхсәт бирү турында гариза кергән көннән алып унбиш эш көне эчендә әзерләнә һәм «Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкы катнашында гавами тыңлауларда каралырга тиеш.».

1.2. 26 статьяның 7 өлешендәге 4 абзацында «ундүрт көн» сүзләрен «җиде эш көне» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 29 статьяда:

4 өлештә «ункөн» сүзләрен «биш эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

5 өлешнең 4,5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- капиталь төзелеш объектының әлеге статьяның 5 өлеше нигезендә төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш, төзелешкә рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

- капиталь төзелеш объектының төзелгән, реконструкцияләнгән проект документациясе параметрларының туры килмәве, әлеге статьяның 5 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.1 өлеш өстәргә:

«5.1. Мондый объектның техник планында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектының мәйданы турындагы белешмәләрнең аермасы проект документациясендә һәм (яисә) төзелешкә рөхсәт бирүдә күрсәтелгән капиталь төзелеш объектының мәйданы турындагы күрсәткечләргә карата биш проценттан да артмый икән, әгәр дә техник планда күрсәтелгән катлар, биналар (булган очракта) һәм машина урыннары саны(булган очракта) проект документациясе һәм (яисә) төзелешкә рөхсәт бирү белән туры килсә, бу объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигез була алмый.».

1.4. 30 статьяда:

2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 6 абзац өстәргә:

«территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул итү.».

3өлешне түбәндәге эчтәлекле 7 һәм 8 абзацлар белән тулыландырырга:

«- Россия Федерациясе тарафыннан төзелгән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы яисә юридик зат (алга таба - Россия Федерациясе тарафыннан билгеләнгән юридик зат);

- Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы, территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул иткән җирле үзидарә органы, Россия Федерациясе субъекты тарафыннан төзелгән һәм Россия Федерациясе субъекты кабул иткән территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик зат (алга таба - Россия Федерациясе субъекты тарафыннан билгеләнгән юридик зат) тарафыннан, яисә территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыру максатларында территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат тарафыннан.»;

5, 6 өлешләрдә «утызкөн эчендә» сүзләрен «егерме биш көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

13 өлештә «конкрет территориаль зона өчен билгеләнгән,» сүзләреннән соң «шулай ук территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул итүгә бәйле рәвештә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр әзерләнгән очракта,» сүзләрен өстәргә, «мондый шәһәр төзелеше регламенты» сүзләреннән соң «, комплекслы үсеш узарга тиешле территория чикләрендә» сүзләрен өстәргә;

1.5. 35.1 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«35.1 статья. Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары.**

**Ж-1Индивидуаль торак йортлар салу зонасы.**

Ж-1 индивидуаль торак йортлары белән төзелеш зонасы аерым торучы һәм блокланган индивидуаль торак йортлардан (коттеджлардан), йорт янындагы җир кишәрлекләреннән яки алардан башка җирле әһәмияттәге хезмәт күрсәтүләрнең минималь рөхсәт ителгән җыелмасыннан торак районнарны формалаштыруның хокукый шартларын тәэмин итүөчен бүлеп бирелгән.

Рөхсәт ителгән файдалануның төп төре объектлары территориянең кимендә 60 процентын биләргә тиеш. Территориянең 40 %ына кадәр объектларны файдалануның рөхсәт ителгән төп төрләренә карата ярдәмче урыннар урнаштыру өчен файдалану рөхсәт ителә.

**Күчемсез милекне рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре:**

- индивидуаль торак йортлар;
- блокланган торак йортлар.

**Рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре:**

- Аерым торучы яисә торак йортларга төзелгән гаражлар яисә ачык автостоянкалар: шәхси кишәрлеккә 2 машина урыны;
- - хуҗалык корылмалары;
- яшелчә бакчалары, җимеш бакчалары, түрбакчалар;
- теплицалар, оранжереялар;
- су саклау өчен индивидуаль резервуарлар, су алу өчен скважиналар, индивидуаль коелар;
- индивидуаль мунчалар, бәдрәфләр;
- янгын сүндерү каравылы җайланмалары (гидрантлар, резервуарлар);
- чүп җыю өчен мәйданчыклар.

**Куллануныңшартлырөхсәтителгәнтөрләре:**

- биеклеге 4 каттан да артмаган, квартир яны участоклары булган яки алардан башка аз катлы күп фатирлы торак йортлар;
- кер юу һәм химчисткаларның кабул итү пунктлары;
- 20 урыннан да артмаган кунакханәләр;
- вакытлыча сәүдә объектлары;
- офислар, банк бүлекләре;
- балалар бакчалары, башка мәктәпкәчәтәрбияобъектлары;
- гомуми белеем бирү мәктәпләре;
- гомумимәйданы 150 квадрат метрдан артмаган беренче зарурлык товарлары кибетләре;
- клублар (мәдәният йортлары);
- китапханәләр;
- мәдәни объектлар;
- фельдшер-акушерлык пунктлары;
- йорт хайваннарын һәм кош-кортны тоту өчен төзелгән биналар (күршеләр белән татулык мөнәсәбәтләрен саклау шарты белән);
- хайваннарны даими карап торучы ветеринария хастаханәләре;
- спорт мәйданчыклары, теннис кортлары;

- спорт заллары, рекреация заллары; эш вакыты буенча чикләнгән күпмаксатлы һәм махсуслаштырылган клублар;
- полиция бүлекчәләре, участок пунктлары;
- элемтә бүлекләре;
- торак - эксплуатация һәм авария-диспетчерлыкхезмәтләре;
- файдалануның хезмәт күрсәтүче һәм коммерцияле төрләре объектлары алдында парковкалар;
- кәрәзле, радиочелтәрле һәм иярчен элемтә антенналары;
- вак көнкүреш ремонты буенча кабул итү пунктлары һәм остаханәләр (аяк киеме, кием-салым, зонт, сәгать һ.б.); 100 кв.метрга кадәр тегү ательелары һәм остаханәләре;
- чәчтарашханә, косметик салоннар, матурлык салоннары;
- һәйкәлләр һәм истәлекле билгеләр.

**Җир кишәрлекләренең чик күләмнәре:**

Рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме:

- бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек өчен - 400 кв.м.;
- индивидуаль торак төзелешен алып бару өчен - 1000 кв.м.;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен - 1000 кв.м.;
- торак пунктның читендә (кыр җир кишәрлеге) - 1000 кв.м.

Рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең максималь күләме:

- бакчачылыкны, яшелчәчелек, терлекчелекне алып бару өчен - 1500 кв.м.;
- индивидуаль торак төзелешен алып бару өчен - 1500 кв.м.;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен - 2500 кв.м.;
- торак пункт читендә (кыр җир кишәрлеге) - 5000 кв.м.

**Ж-1П. Перспективалыторактөзелешезонасы**

Перспективалы торак төзелеше зонасы планлаштырылучы, Кайбыч муниципаль районын һәм Олы Кайбыч авыл җирлеген территориаль планлаштыру документлары нигезендә, җирле әһәмияттәге хезмәт күрсәтүләрнең минималь рөхсәт ителгән җыелмасы булган шәхси торак йортлар белән аерым торучы йортлар төзү өчен бүлеп бирелгән.

Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре, рөхсәт ителгән файдалануның чикле параметрлары, Ж-1П зонасы өчен җир кишәрлекләренең төзелешенә карата таләпләр җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләренә, Ж-1 зонасы өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренең чикле параметрларына һәм төзелеш таләпләренә туры килә.».

2. Әлеге карарның 1 пунктының 1.5 пунктчасында каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) үлчәмнәре әлеге карар рәсми рәвештә үз көченә кергәннән соң гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренә (яңа бүлеп бирелә торган җир кишәрлекләренә) кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1.5 пунктының 1.5 пунктчасында каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) үлчәмнәре әлеге карарны кабул иткәнче гражданнарга аренда хокукларында бирелгән һәм гамәлдәге

законнарда билгеләнгән тәртиптә алар сатып ала торган җир кишәрлекләренә кагылмый дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2021 елның 26 августындагы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 сентябрендәге 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» гы 26 номерлы карарын юкка чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Кайбыч авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе А.И.Рәхмәтуллин